СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 1А, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 1А йорты, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**«30» октябрь 2023 ел** **№1**

**Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылында Яңа Кишет авылы, Дружба урамы, 100а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылында Яңа Кишет авылы, Дружба урамы, 100а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылында Яңа Кишет авылы, Дружба урамы, 100а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1 нче этап: Молодежная урамында яшәүчеләр;

2 нче этап: Мира урамында яшәүчеләр;
3 нче этап: Дружба урамында яшәүчеләр .

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Яңа Кишет авылында Мира, Молодежная, Дружба урамнарының урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Яңа Кишет авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

6. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дружба урамы, 100а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Ф.И.Ахмадуллин